ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2019 г.Мензелинск № 341

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча Планнарны эшләүгә Таләпләрне раслау турында

1994 елның 21 декабрендәге “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында”гы №68-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 августындагы “Нефть һәм нефть продуктлары агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча кичектергесез чаралар турында”гы №613 карары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2004 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча планнарны эшкәртү һәм кисәтү Кагыйдәләрен раслау турында”гы №621 боерыгы нигезендә, нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә аларның зарарлы тәэсиреннән халыкны һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча Планнарны эшләүгә Таләпләрне расларга.

2. Нинди хосусыйлыкта булуына карамастан, Минзәлә муниципаль район территориясендә нефть һәм нефть продуктларын эшкәртү, транспортировкалау, саклау һәм файдалануны башкаручы оешмаларга нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча планнар эшләргә һәм гамәлдәге билгеләнгән законнар тәртибендә, гамәлдәге карарның 1 нче пункты белән расланган Таләпләр нигезендә аларга төзәтмәләр кертергә рекомендация бирергә.

3. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе, Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе Р.Ф.Ягафаровка йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты карары
белән расланган
дата _________ 20___ №______

# Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча Планнарны эшләүгә Таләпләр

1.Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча Планнарны эшләүгә гамәлдәге Таләпләр (алга таба – Таләпләр) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 августындагы “Нефть һәм нефть продуктлары агуын кисәтү һәм ликвидацияләү турында”гы №613 карары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2004 елның 28 декабрендәге №621 боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктларының агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча планнарны эшләү һәм килешү Кагыйдәләре нигезендә эшләнгән.

Гамәлдәге Таләпләр локаль һәм муниципаль әһәмияттәге гадәттән тыш хәлләргә, шулай ук аларны ликвидацияләү өчен җәлеп ителгән көч һәм чараларның үзара бәйләнешен оештыруга караган Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы территориясендә нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча Планнарны (алга таба – Планнар) формалаштыру принципларын билгели.

2. Планнар түбәндәге объектлар өчен билгеләнә торган, аккан нефть һәм нефть продуктларының максималь мөмкин булган күләмен исәпкә алып, гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә эшләнә:

нефть салынган судно - 2 танк;

нефть салынган баржа – гомуми йөк күтәрүчәнлекнең 50 проценты;

стационар нефть чыгаручы корылмалар һәм нефть терминаллары -1500 тонна;

автоцистерна –100 процент күләмдә;

нефть базасы, нефть саклагыч – иң зур резервуарның 100 проценты;

тимер юл составы – тимер юл составында цистерналарның гомуми күләменең 50 проценты;

үткәргеч торба өзелгәндә – 6 сәгать дәвамында чыгарылган максималь күләмнең 25 проценты һәм үткәргеч торбаның өзелгән участогында ябу биге арасындагы нефть күләме;

үткәргеч торба тишелгәндә – 14 көн дәвамында чыгарылган максималь күләмнең 2 проценты;

нефть һәм нефть продуктлары саклануның стационар объектлары –бер саклау объектының максималь сыешы күләменең 100 проценты.

3. Нефть һәм нефть продуктларының агуы гадәттән тыш хәл буларак классификацияләнә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә ликвидацияләнә.

Урында нефть һәм нефть продуктлары агу күләме һәм мәйданына бәйле рәвештә, эчке төче сулы сулыкларда түбәндәге категорияләрдә гадәттән тыш хәлләр билгеләнә:

локаль әһәмияткә ия – нефть һәм нефть продуктлары агуның аскы дәрәҗәсеннән объект территориясендә нефть һәм нефть продуктларының 100 тоннага кадәр агуы;

муниципаль әһәмияткә ия – муниципаль районның административ чикләрендә нефть һәм нефть продуктларының 100-500 тоннага кадәр агуы, яисә объект территориясе чикләреннән чыгучы нефть һәм нефть продуктларының 100 тоннага кадәр агуы;

территориаль әһәмияткә ия – муниципаль районның административ чикләрендә нефть һәм нефть продуктларының 500-1000 тоннага кадәр агуы, яисә объект чикләреннә чыгучы нефть һәм нефть продуктларының 100-500 тоннага кадәр агуы.

Аккан урыннан һәм гидрометеорологик шартлардан чыгып, гадәттән тыш хәлнең категориясе күтәрелергә мөмкин.

Гадәттән тыш хәлләрне территориаль, региональ һәм федераль әһәмияттәге гадәттән тыш хәлләргә кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 августындагы “Нефть һәм нефть продуктларының авария нәтиҗәсендә агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча кичектергесез чаралар турында”гы №613 Карары нигезендә башкарыла.

4. План белән түбәндәгеләр күздә тотылырга тиеш:

а) нефть һәм нефть продуктларының агуы мөмкин булуын фаразлау, нефть һәм нефть продуктларының агуы мөмкин булган күләмен фаразлау, нефть табы таралуын фаразлау (сулыкларга, су агымына һб.ларга эләгү мөмкинлеге), аварияләр куркынычы югары булган урыннарны билгеләү;

б) нефть һәм нефть продуктлары агуы белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне диквидацияләү өчен көч һәм чаралар саны (алга таба – көч һәм чаралар), объектта булган көч һәм чараларның ликвидация бурычларын тәңгәл килүе һәм һөнәри авария-коткару формированиеләрен җәлеп итү зарурлыгы;

в) көч һәм чараларның үзара бәйләнешен оештыру;

г) көч һәм чаралар составы һәм дислокация;

д) идарә итү, элемтә һәм хәбәр итүне оештыру;

е) билгеләнгән дәрәҗәдәге әзерлек өчен җаваплылык алган оешмаларның көч һәм чараларның даими әзерлеген тәэмин итү тәртибе;

ж) нефть һәм нефть продуктлары агуын ликвидацияләүдә катнашучы оешмалар арасында мәгълүматны үзара алмашу системасы;

з) гадәттән тыш хәлләр турында сигнал алганда беренчел гамәлләр;

и) ликвидацияләү буенча операция оештырганда һәм уздырганда исәпкә алына нефть һәм нефть продуктлары аккан районның географик, навигацион-гидрографик, гидрометеорологик һәм башка үзенчәлекләре;

к) халыкның иминлеген тәэмин итү һәм медицина ярдәме күрсәтү;

л) нефть һәм нефть продуктлары агуын ликвидацияләү буенча операцияләр уздыру графигы;

м) нефть һәм нефть продуктлары агуын ликвидацияләү буенча операцияләрнең матди-техник, инженерлык һәм финанс тәэмин ителешен оештыру.

5. Көч һәм чараларның тиешле санын исәпләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алынырга тиеш:

а) аккан нефть һәм нефть продуктларының максималь мөмкин булган күләме;

б) түгелгән мәйдан;

в) объектны гамәлгә кертү елы һәм соңгы капиталь ремонт ясалган ел;

г) объектта нефть һәм нефть продуктларының максималь күләме;

д) нефтьнең һәм нефт продуктларының физик-химик үзлекләре;

е) объект урнашкан урынның нефть һәм нефть продуктлары таралу тизлегенә тәэсире (аларның диңгез, елга акваторияләренә, эчке сулыкларга эләгү мөмкинлеген исәпкә алып);

ж) объект урнашкан урында гидрометеорологик, гидрогеологик һәм башка шартлар;

з) объектта булган көч һәм чараларның, шулай ук РФ субъектында, муниципаль районда дислокацияләнгән һөнәри авария-коткару формированиеләренең мөмкинлекләре (нефть һәм нефть продуктлары агуын ликвидацияләүдә катнашуга аларның язмача килешүе булган шартта);

и) нефть калдыкларын күчерү, саклау һәм эшкәртү буенча полигоннар булу;

к) нефть һәм нефть продуктлары агу мөмкин булган районда транспорт инфраструктурасы;

л) гадәттән тыш хәл булган урынга көч һәм чараларны китерү вакыты;

м) нефть һәм нефть продуктлары агуын локализацияләү вакыты: акваториягә акканда – 4 сәгатьтән артык булмаган һәм туфракка акканда 6 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә.

6. Нефть һәм нефть продуктлары агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча гамәлләрне планлаштыру дәрәҗәсе нефт һәм нефть продуктлары агуны гадәттән тыш хәлләргә кертү өчен нефть һәм нефть продуктлары агуның түбән дәрәҗәсе зурлыгын билгеләүче норматив хокукый актлардагы таләпләр нигезендә башкарылырга тиеш.

7. Планнарны эшкәртүне оештыру, аларны килешү һәм раслау тәртибе, планнар һәм аларга кушымталар структурасы, планнар экспертизасы, планнарны кертү һәм аларны гамәләгә кертү сроклары Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2004 елның 28 декабрендәге “Россия Федерациясе территориясендә нефть һәм нефть продуктлары агуын кисәтү һәм ликвидацияләү буенча планнарны эшкәртү һәм килешү Кайгыдәләрен раслау турында”гы №621 боерыгы нигезендә башкарыла.

8.Нефть һәм нефть продуктлары агуын ликвидацияләү буенча эшләр уздыру турындагы отчет “Минзәлә муниципаль районының гражданнарны саклау идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе аша Минзәлә муниципаль районында Гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиягә тапшырылырга һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

а) нефть һәм нефть продуктлары агуның сәбәбе һәм торышы;

б) нефть һәм нефть продуктлары агу нәтиҗәләрен ликвидацияләү һәм локальләштерү, агу чыганагын бетерү барышында идарә органнарының гамәлләрен тасвирлау һәм бәя бирү;

в) нефть һәм нефть агуны ликвидацияләү буенча эш барышында кулланыла торган көч һәм махсус техник чараларның нәтиҗәлелегенә бәя бирү;

г) нефть һәм нефть продуктлары агуны ликвидацияләү буенча эш уздыруга чыгымнар (локальләштерү, нефть һәм нефть продуктларын җыю һәм территорияне алга таба тернәкләндерүгә чыгымнарны кертеп);

д) су биологик ресурсларына килгән зыянны каплауга чыгымнар (компенсация);

е) нефть һәм нефть продуктлары агуны ликвидацияләү буенча эшләрне башкарганнан соң территорияләрдә (акваторияләрдә) калган пычрану дәрәҗәсе;

ж) оешманың техник җиһазлары торышы, аның техник торышындагы кимчелекләрне, нормаларны һәм сәнәгать куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча кимчелекләрне бетерү турында күзәтчелек органнарының күрсәтмәләре;

з) оешмалар формированиеләрен (подразделениеләрен) һәм һөнәри авария-коткару формированиеләрен (хезмәтләре) өстәмә тәэмин итү буенча тәкъдимнәр.

Тиешле карталар (планнар), исәп-хисап, графиклар, башка белешмә материаллар белән бергә күрсәтелгән отчет Минзәлә муниципаль районында Гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясендә кимендә 5 ел саклана.

9. Локаль һәм җирле әһәмияттәге нефть һәм нефть продуктлары агуны ликвидацияләү өчен җәлеп ителгән көч һәм чараларны тикшерү вакытын һәм тәртибен Минзәлә муниципаль районында Гадәттән тыш хәлләрне булдырмау һәм ликвидацияләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясе билгели.